

Рузаевка жире талантлы язучыларга, шагыйрьләргә, укытучыларга, табибларга, музыкантларга бай. Һәм, әлбәттә, рәссамнарга.
2023 елнын 13 ноябре Рузаевка рәссамы - графигы Владимир Иванович Бирлюков тормышында мөһим вакыйга - 75 еллык юбилей датасы танылган.
Рәссамнын шәхси кvргәзмәләрендә булып, Владимир Бирлюковнын атаклы “Рузаевка альбомы»н ачкач, искиткеч картиналар галереясына элэгэсен. Бу тарихи әсәрләр дә, лирик пейзажлар да. Владимир Иванович картиналарынын сюжетлары гади, әмма аларда кvпме мавыгу бар! Алар тирән эчтәлек белән аерылып торалар, барысын да vз чынбарлыгы белән жәлеп итәләр. Аларда без туган якны кvрәбез. Гажәеп картиналарга карап, син vзен дә сизмәстән кайнар чын тормышны тоясын: жир исе, чык тамчылары, кошларнын тавышларын, агачларнын тыныч пышылдавын ишетәсен. Рәссам-мастер Туган илне рәсемгә тошерә. Барлык эшләр, башкарунын виртуозлыгы аркасында, “мажорно” янгырый. Анын йоздән артык картинасы бар. Бу - Рузаевка, Мордовия, Россиянен алтын фонды. Анын эшләренен тәрбия кыйммәте югары. Аларда табигать гармониясен, буыннар бәйләнешен кvрәбез: vз жиребезнен патриот - гражданы тәрбиясендә рәсем сәнгатенен боек кочен кvрәбез.
Владимир Иванович даими эшли, каләм рәсеме техникасын камилләштерә. Бу тырыш хезмәтне таләп итә. Безнен герой - арымый-талмый эшләvче, туган як патриоты. Үз тормышынын топ мәгънәсен ул хезмәт, сәнгатькә мәхәббәт дип саный. Бу мөһим сыйфатларны юбиляр vзенен бәхетле шәкертләренә тапшыра алган. Укытучы алар турында очрашуларда һәрвакыт горурлык белән сойли. Бу Сергей Кузнецов, Мәскәvдә рәссамнарнын vзәк йортында эшли; Александр Фадеев Парижда, Луврда доньянын ин танылган сәнгать музейларынын берсендә картиналар реставраторы булып эшли; Фролова Людмила Иваново олкәсенен Палех бистәсендә рәссам; Бедина Валентина Комсомольск бистәсенен сәнгать мәктәбе директоры. Бу исемлек дәвам итә ала. Менә ул укытучы очен топ бvләк.
Рәссам-ижатчы халыкара, тобәкара, Мордовия шәхси кvргәзмәләрдә, конкурсларда, смотрларда актив катнашучы. Бvген Эрьзя музеенда Россия рәссамнар берлеге әгъзасы Владимир Иванович Бирлюковнын сигезенче шәхси кvргәзмәсе уза. “Тушь, перо” техникасында 40 рәсем тәкъдим ителгән, алар гель ручкасы белән дә башкарылган.
Ә балалар белән кvпме кызыклы очрашуларны В.И.Бирлюков безнен мәктәптә vткәрә, аларны оештыручылар - 10 нчы мәктәп укытучылары, 6 нчы, 2 нче китапханә-филиал модирләре Надежда Валентиновна Колчина һәм Надежда Александровна Зайцева. Бу чын ижат дәресләре, тормыш дәресләре иде.
Без Владимир Иванович Бирлюковка 1980 елларда 10 нчы мәктәпне бизәvгә, шулай ук музей ачуга керткән бәяләп бетергесез олеше очен рәхмәт белдерәбез. Ул патриотик форумнарда, анын куллары белән тозелгән музейда Батырлык дәресләрендә актив катнашучы. Рәссам-график vзенен Боек Ватан сугышы турындагы картиналарын туган музеена бvләк итте. Анын әтисе, Иван Афанасьевич, Сталинград сугышында катнашучы. Анын турында фотоматериал музейда саклана. Ә Владимир Иванович ул вакыттагы

коточкыч вакыйгалар истәлеген картиналарда саклый.
Хормәтле Владимир Иванович, титаник хезмәтегез рәссамнын боек бvләге, талант коче, ижади потенциалы, жан юмартлыгы, тыйнаклыгыгыз очен зур рәхмәт сезгә!
Сезнен патриотизм дәресләре, осталык дәресләре, әхлак чыганаклары очен рәхмәт! Без сезнен белән горурланабыз, сезне кадерлибез! Сәламәтлек, тынычлык, яна оригиналь картиналар, ижади унышлар сезгә сәнгать доньясында

**Фәризә БАТОРШИНА**, *Рузаевка шәһәре 10нчы мәктәбенен Педагогик хезмәт ветераны*